# Татар халык уеннары



49 нчы балалар бакчасы тәрбиячесе:
Бадертдинова Резеда Раисовна

*"Хәтердән башка йолалар, тәрбиядән башка рухи хәзинә, рухи хәзинәдән  башка шәхес, ә шәхестән башка халык - тарихсыз“.*





# Максатлар:

1. Балаларда татар халкына хөрмәт һәм аны ярату, рухи кыйммәт һәм кешелек дөньясының аралашу, белем алу чарасы буларак аңлы караш тәрбияләү;
2. Балаларның сөйләү һәм фикерләү сәләтен үстерү, аларны татар әдәби телен тормышның төрле өлкәләрендә ирекле куллана алырлык шәхесләр итеп тәрбияләү; дөрес сөйләм эшчәнлегенең үзара аралашу чарасы икәнен белдерү;
3. Телне өйрәнгәндә үзләштергән белем һәм күнекмәләрне сөйләмдә дөрес куллана белү.
4. Халкыбызның бай рухи дөньясы белән танышуны дәвам итү;
5. Татар халкы белән горурлану хисләре тәрбияләү өстендә эшләүне дәвам итү..
6.Халык уеннары аша балаларда тырышлык,түземлек,гаделлек сыйфатлары тәрбияләү.

# Бурычлар

- балаларда сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрен үстерү һәм телне аралашу чарасы буларак барлык ситуацияләрдә татар халык уеннарын куллану;

-халык уеннары аша баларның сөйләм телен үстерү;

-аралашу осталыгы һәм иҗади сәләт арасында бәйләнеш булдыру;

-балаларның образлы, логик фикерләү сәләтен үстерү, аларда аралашу культурасы күнекмәләре тәрбияләү.





## ***Халык уеннары уздыруның методикасы:***

-Уен хәрәкәтләрен эчтәлеге,кагыйдәләре балаларның яшь үзенчәлекләренә, мөмкинлекләренә , дөньяны күзаллауларына,яңалыкка омтылышларына туры килергә тиеш;

- Балаларга уен кагыйдәләрен алыштырырлык, хәрәкәтләрне аңлатырлык әдәби текстны куллану;

- Үз мөмкинлекләреңне бәяләү, тормыш тәҗрибәсен куллану;

-Үз фикереңне әйтә белү;

-Балалар төркеменең яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу;

- Төркемнең гомуми хәлен исәпкә алу;

-Уенны сайлау ел фасылының,һава торышын, булган күрсәтмәлелекне, исәпкә алырга тиеш.





***Уенга әзерләнү:***

- Тәрбиячнең уеннарның эчтәлеге белән танышуы;
- Уенны уздыруга әзерләнү;
- Уен уйналасы бүлмәнең гигиеник торышы;
- Уен өчен уңай шартлар тудыру;
- Кирәк-яраклар,төрле җиһаз кулланмалар әзерләү;
- Баларны уен бклән кызыксындыру.







“Кәрия- Зәккәрия” уены күренеше

# Татар халык уены «Бүләкләр»







Туган көннәрдә

“Ак калач”

уенын бик

яратып уйныйбыз









Музей бүлмәсендә күңелле ял итәбез

“Яшерәм яулык”

уены күренеше





## *“Агыйдел”*

Балалар парлашып бер-бер артлы басалар. Бер бала парсыз кала, ул алга чыга. Кушымтаны җырлаганда, балалар кулларын бер-берсенә тотынган килеш өскә күтәрәләр (күпер ясыйлар). Шул вакытта парсыз бала күпер аркылы чыга һәм үзенә ошаган баланы сайлый. Уен дәвам итә.

Агыйделнең суларында
Ак чиләгем күмелде.
Әйдә, дустым, безнең якка
Безнең яклар күңелле.

Кушымта:

Зәңгәр чәчәк жыя-җыя,
Зәңгәрләттем кулымны.
Бергә-бергә уйныйк әле,
Бир, дускаем, кулыңны.





## ***“Түбәтәйле”***

Уртада 5-6 урындык тора, урындыкларга түбәтәйләр куела. Балалар урындыклар тирәли басалар, көй башлануга, җиңелчә йөгерә башлыйлар. Көй туктауга, түбәтәйләрен кияләр, шул арада урындыкларга утырып өлгерергә тиешләр. Кем урынсыз кала, шул уеннан чыга. Икенче мәртәбә уйнаганда уртада өч урындык кала, уйнаучылар саны артыграк була. Соңга таба бер урындык калдыралар. Шулай итеп иң игътибарлы, җитез бала билгеләнә.





# Киңәшләр:

Уенны башка шөгыль белән алыштырырга тырышмагыз.

Уенны бала тормышының барлык өлкәләрендә дә кулланыгыз.

Бала  уенга чакырса, шатланыгыз, димәк ул сезне үз итә һәм сезгә ышана.

Бала белән уйнаганда, үзегезнең олы кеше икәнлегегезне онытыгыз.

Балага уеннан “мәхрүм итү җәза”сын бирмәгез.

Уен кагыйдәләрен бозган балага тынычрак карарга тырышыгыз.

Уен вакытында рольләрне көчләп такмагыз.

Чираттагы эш көненә әзерләнгәндә, һәр яңа уенның балага иң яхшы бүләк икәнен исегездән чыгармагыз!





Игътибарыгыз
өчен
рәхмәт!



